**ГЛАВНОЕ АРХИВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ПРИ КАБИНЕТЕ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН (ТАТГЛАВАРХИВ)**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ КАРШЫНДАГЫ БАШ АРХИВ ИДАРӘСЕ (ТАТБАШАРХИВ)**

БОЕРЫК

31.03.2016 Казан шәһәре № 033 – од

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы УП-569 номерлы Указы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Әлеге боерыкка 1 нче кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәне расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык вазыйфаларын башкаручы Р. Ә. Шәйхетдинова

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
каршындагы Баш архив
идарәсенең 31.03.2016 № 033 -
од боергы белән расланды

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы нигезендә эшләнде.

Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясен (алга таба – Комиссия) формалаштыру тәртибе һәм эшчәнлеге тәртибе билгеләнә.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссиянең төп бурычы түбәндәгечә ярдәм күрсәтүдән гыйбарәт:
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив

идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре, Идарә) чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәүне тәэмин итүдән, шулай ук «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны (алга таба – хезмәттәге тәртипкә карата таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләр) үтәүне тәэмин итүдән;

Идарәдә коррупцияне кисәтү чараларын гамәлгә ашырудан.

1.4. Комиссия Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә (моңа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вазыйфаларына билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләре керми) карата хезмәттәге тәртипкә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләрне карый.

1.5. Идарәдә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вазыйфаларына билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә карата хезмәттәге тәртипкә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында төзелгән Хезмәттәге тәртипкә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе карый.

1.6. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр уздырмый.

## II. Комиссия составы

2.1. Комиссия Идарә боерыгы белән төзелә. Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия әгъзалары арасыннан Идарә башлыгы тарафыннан билгеләп куела торган, Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия секретаре һәм әгъзалары керә. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары үти.

2.2. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) Идарә башлыгы урынбасары (Комиссия рәисе), коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат (Комиссия секретаре), Дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторыннан дәүләт хезмәткәрләре, Идарәнең юридик секторы мөдире, Идарәнең Идарә башлыгы тарафыннан билгеләнүче башка бүлекчәләре вәкилләре;

б) Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт идарәсенең һәм (яисә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре бүлекчәсе вәкиле;

в) эшчәнлеге дәүләт хезмәтенә бәйле фәнни оешмалар, һөнәри мәгариф оешмалары, югары белем мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем мәгариф оешмалары вәкиле (вәкилләре).

2.3. Идарә башлыгы Комиссия составына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив каршындагы Иҗтимагый совет, Идарәнең башлангыч һөнәр оешмасы вәкилләрен кертү турында карар кабул итәргә мөмкин.

2.4. Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына Идарә башлыгы гарызнамәсе нигезендә, тиешле органнар һәм оешмалар белән килештереп, билгеләнгән тәртиптә кертелә.

2.5. Комиссиянең Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләмәүче әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми санының дүрттән береннән дә ким булмаска тиеш.

2.6. Комиссия составы мәнфәгатьләр конфликтына китермәслек итеп һәм Комиссиянең кабул ителә торган карарларына йогынты ясамаслык итеп формалаштырыла.

2.7. Комиссия утырышларында хәлиткеч тавыш хокукы белән түбәндәгеләр катнаша:

а) Комиссия тарафыннан үзенә карата хезмәттәге тәртипкә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга таләпләрне үтәү турындагы мәсьәлә каралучы дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә торган, үзенә карата шушы мәсьәлә каралучы дәүләт хезмәткәре биләүче шундый ук дәүләт вазыйфасында Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче ике дәүләт хезмәткәре;

Идарадә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча һәм Комиссия караучы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә алырлык белгечләр; башка дәүләт органнарың, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; кызыксынучы оешмалар вәкилләре; Комиссия тарафыннан үзенә карата хезмәттәге тәртипкә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга таләпләрне үтәү турында мәсьәлә каралучы дәүләт хезмәткәренең вәкиле – үзенә карата шушы мәсьәлә каралучы дәүләт хезмәткәренең яисә Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының үтенечнамәсе нигезендә – Комиссия рәисенең Комиссия утырышына кимендә өч көн кала һәр конкрет очрак өчен аерым-аерым кабул ителә торган карары буенча.

2.8. Комиссия утырышы, анда Комиссия әгъзаларының гомуми санының кимендә өчтән икесе катнашкан очракта, тулы хокуклы дип санала. Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары катнашында гына утырышларны уздыру рөхсәт ителми.

2.9. Комиссия әгъзасының Комиссия утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда мәнфәгатьләр конфликтына китерерлек турыдан-туры яисә читтән шәхси кызыксынуы барлыкка килгәндә, ул утырыш башланганчы ук бу хакта хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта Комиссиянең тиешле әгъзасы әлеге мәсьәләне караганда катнашмый.

## III. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия утырышын уздыру өчен түбәндәгеләр нигез була:

а) дәүләт хезмәткәре тапшырган белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы буенча, дәүләт хезмәткәренең хезмәттәге тәртипкә таләпләрне үтәвен Россия

Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә уздырылган тикшерү йомгаклары буенча Идарә башлыгы тарафыннан түбәндәгеләрне таныклаучы тикшерү материалларын тапшыру:

дәүләт хезмәткәренең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турындагы белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәдә каралган дөрес булмаган һәм тулы булмаган белешмәләр тапшыруы хакында, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган белешмәләрне бирмәве турында;

дәүләт хезмәткәренең хезмәттәге тәртипкә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәве хакында;

б) Идарәнең норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә хокук һәм кадрлар бүлегенә кергән түбәндәгеләр:

Идарәдә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре тапшырырга тиешле керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турындагы белешмәләрне, шулай ук хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турындагы белешмәләрне бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәткәрләренең Идарә боерыгы белән расланган исемлегенә кертелә торган дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданның коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамәләр нигезендә эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) ризалык бирүе турындагы мөрәҗәгате, әгәр дәүләт хезмәткәре дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел узганчы аның вазыйфаи (хезмәттәге) бурычлары шушы оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләренә кергән булса;

дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр аркасында хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турында белешмәләрне бирергә мөмкинлеге булмау хакындагы гаризасы;

территориясендәге банкта счетлары (кертемнәре) булган, акчалары һәм кыйммәтләре саклана торган һәм (яисә) чит илләр финанс инструментларына ия булган дәүләтнең законнары нигезендә компетентлы органнар тарафыннан кулга алынган яисә аның ихтыярына яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган баларының ихтыярына бәйле булмаган бүтән сәбәпләр буенча счетлардан (кертемнәрдән), акчаларыннан һәм кыйммәтле нәрсәләреннән һәм (яисә) чит илләр финанс инструментларыннан файдалану һәм аларга ия булу тыелуга бәйле рәвештә «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалар һәм кыйммәтле нәрсәләр саклауны, чит илләр финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмау хакында дәүләт хезмәткәренең гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерерлек яисә мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булырлык шәхси кызыксынуы турында хәбәрнамәсе;

в) Идарә башлыгының яисә Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәттәге тәртипкә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәвен тәэмин итүгә йә Идарәдә коррупцияне кисәтү чараларын гамәлгә ашыруга кагылышлы хәбәрнамә тапшыруы;

г) Идарә башлыгының дәүләт хезмәткәренең «Дәүләт хезмәте вазыйфаларын билүче затларның һәм бүтән затларның чыгымнары керемнәренә туры килүне тикшереп тору турында» 2012 елның 03 декабрендәге номерлы 230-ФЗ Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган дөрес булмаган һәм тулы булмаган белешмәләр бирүен таныклаучы тикшерү материалларын тапшыруы;

д) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 статьясы нигезендә Идарәгә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмадан Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын үтәүче граждан белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яисә граждан-хокукый шартнамә төзү хакында хәбәрнамә, әгәр шушы оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның Идарәдә вазыйфа биләгән чорында башкарыла торган вазыйфаи (хезмәттәге) бурычларына кергән булса, әлеге гражданга элегрәк Комиссия тарафыннан шушы оешма белән хезмәт һәм граждан-хокукый мөнәсәбәтләргә керү кире кагылмаган булса яисә мондый гражданга коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләвенә һәм коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) ризалык бирү хакындагы мәсьәлә Комиссия тарафыннан каралмаган булса.

3.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгать Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче граждан тарафыннан Идарәнең кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау буенча җаваплы вазыйфаи затына тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган датасы, яшәү урынының адресы, дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң соңгы ике ел эчендә биләгән вазыйфалары, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешманың урнашкан урыны атамасы, аның эшчәнлеге характеры, граждан дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән чорда үтәгән вазыйфаи (хезмәттәге) вазыйфасы, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмага карата дәүләт идарәсе буенча функцияләре, шартнамә төре (хезмәт яисә граждан-хокукый), аның күз алдында тотыла торган гамәлдә булу срогы, шартнамә буенча эшләр башкарган (хезмәтләр күрсәткән) өчен түләнүче сумма. Идарәнең кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау буенча җаваплы вазыйфаи заты мөрәҗәгатьне карый, аның нәтиҗәләре буенча, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы таләпләрне исәпкә алып, мөрәҗәгать асылы буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәтеннән китәргә планлаштырган дәүләт хезмәткәре тарафыннан бирелергә мөмкин һәм Комиссия тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә каралырга тиеш.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә Идарәнең кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карала, бу җаваплы вазыйфаи зат Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасы биләүче гражданның «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы таләпләрне үтәве турында дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамә кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карала, ул исә хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

3.4.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә яисә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне әзерләгәндә Идарәнең кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты мөрәҗәгать яисә хәбәрнәмә тапшырган дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә уздырырга, аңардан язма аңлатулар алырга хокуклы. Идарә тарафыннан мәгълүмат алу өчен дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга гарызнәмәләр җибәререлергә мөмкин. Мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә кергән көннән соң җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Гарызнамәләр җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә кергән көннән соң 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Әлеге срок Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма бу озайту 30 көннән дә артмаска тиеш.

3.5. Комиссия рәисе үзенә Идарә боерыгында каралган һәм Комиссия утырышы уздыру өчен нигезләре булган мәгълүмат кергән очракта түбәндәгеләрне башкара:

а) 10 көнлек срокта Комиссия утырышын уздыру датасын билгели. Бу чакта Комиссия утырышын уздыру датасы әлеге мәгълүмат кергән көннән 20 көннән дә соңга калмыйча билгеләнергә тиеш, моңа әлеге Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында каралган очраклар керми;

б) үзенә карата хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәү мәсьәләсе Комиссия тарафыннан карала торган дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында катнашучы башка затларны кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затына кергән мәгълүмат белән һәм аны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән затларны Комиссия утырышына чакыру турындагы үтенечнамәне карый, аларны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау турында (караудан баш тарту турында) карар кабул итә.

3.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацында күрсәтелгән гаризаны карау буенча Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр кертү өчен билгеләнгән срок узган көннән бер айдан да соңга калмыйча уздырыла.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (пландагы) утырышында карала.

3.8. Комиссия утырышы үзенә карата хезмәттәге тәртипкә таләпләрне үтәү һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәре яисә Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче граждан барында уздырыла. Дәүләт хезмәткәренең яисә Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданның әлеге мәсьәләне аңардан башка карау турындагы язма үтенече булганда Комиссия утырышы аңардан башка гына уздырыла. Дәүләт граждан хезмәткәре яисә граждан Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә күрсәтә.

3.8.1. Комиссия утырышы түбәндәге очракта дәүләт граждан хезмәткәре яисә граждан булмаганда да уздырылырга мөмкин:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә дәүләт граждан хезмәткәренең яисә гражданның Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтелмәгән булса;

б) Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте булган һәм Комиссия утырышын уздыру вакыты һәм урыны хакында тиешенчә шәхсән хәбәр ителгән дәүләт граждан хезмәткәре яисә граждан Комиссия утырышына килмәгән булса.

3.9. Комиссия утырышында дәүләт хезмәткәренең яисә Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданның (аларның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатып бирүләр тыңлана, шушы утырышка чыгарылган материаллар, шулай ук өстәмә материаллар асыллары буенча карала.

3.10. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашучы затлар Комиссия эше барышында мәгълүм булган белешмәләрне башкаларга җиткерергә хокуклы түгел.

3.11. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берәрсен кабул итә:

а) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турындагы белешмәләрне тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турында

белешмәләрне тапшырулары турында Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрне тулы һәм дөрес дип билгеләргә;

б) әлеге пунктның «а» пунктчасында аталган Нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрне дөрес түгел һәм (яисә) тулы түгел дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия Идарә башлыгына дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә тәкъдим итә.

3.12. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берәрсен кабул итә::

а) дәүләт хезмәткәре хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәгән һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәгән дип билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәмәгән һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәмәгән дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия Идарә башлыгына дәүләт хезмәткәренә карата хезмәттәге тәртипкә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне бозарга ярамаганлыкны күрсәтергә йә конкрет җаваплылык чарасы күрергә тиеш.

3.13. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берәрсен кабул итә:

а) гражданга коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) ризалык бирергә, әгәр шушы оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәттәге) бурычларына кергән булса;

б) гражданның коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләвенә йә коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруына (хезмәт күрсәтүгә) ризалык бирмәскә, әгәр шушы оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәттәге) бурычларына кергән булса, һәм баш тартуны дәлилләргә.

3.14. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берәрсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турындагы белешмәләрне тапшыра алмау сәбәбен объектив һәм ихтирамга лаек дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турындагы белешмәләрне тапшыра алмау сәбәбен ихтирамга лаек түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру чараларын күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти йөкләмәләре турындагы белешмәләрне тапшыра алмау сәбәбен объектив түгел дип һәм әлеге белешмәләрне

тапшырудан читләшү алымы дип танырга. Бу очракта Комиссия Идарә башлыгына дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә тәкъдим итә.

3.15. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берәрсен кабул итә:

а) «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалар һәм кыйммәтле нәрсәләр саклауны, чит илләр финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә каршы торырлык хәлләрне объектив һәм ихтирамга лаек дип танырга;

б) «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалар һәм кыйммәтле нәрсәләр саклауны, чит илләр финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә каршы торырлык хәлләрне объектив түгел һәм ихтирамга лаек түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия Идарә башлыгына дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә тәкъдим итә.

3.15.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берәрсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты килеп чыкмый дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуга китерелә яисә мәнфәгатьләр конфликты китереп чыгарыла дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яисә) дәүләт органы җитәкчесенә мәнфәгатьләр конфликтын җайга сала торган яисә ул барлыкка килүне булдырмый торган чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән дип танырга. Бу очракта Комиссия Идарә башлыгына дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чаралары күрергә тәкъдим итә.

3.16. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия тиешле карар кабул итә.

3.17. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берәрсен кабул итә:

а) «Дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм бүтән затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүне тикшереп тору турында» 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне дөрес һәм тулы дип танырга;

б) «Дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм бүтән затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүне тикшереп тору турында» 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше

нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне дөрес түгел һәм тулы түгел дип таныйрга. Бу очракта Комиссия Идарә башлыгына дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрүне һәм (яисә) чыгымнарны тикшереп тору нәтиҗәсендә алынган материалларны аларның компетенциясе нигезендә прокуратура органнарына һәм (яисә) дәүләт органнарына җибәрүне тәкъдим итә.

3.18. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданга карата түбәндәге карарларның берәрсе кабул ителә:

а) коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) ризалык бирергә, әгәр шушы оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәттәге) бурычларына кергән булса;

б) коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләвенә йә коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруы (хезмәтләр күрсәтүе) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12 статьясы таләпләрен боза дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия Идарә башлыгына әлеге хәлләр турында прокуратура органнарына һәм хәбәр җибәргән оешмага мәгълүмат бирүне тәкъдим итә.

3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а» - «д» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча, шуңа сәбәпләр булганда Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11 – 3.15.1, 3.17 – 3.18 пунктларында каралганга караганда бүтәнрәк карар кабул итә ала. Нигезләр һәм дәлилләр Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

3.20. Комиссия карарларын үтәү өчен Идарәнең норматив хокукый актлары проектлары, Идарә башлыгының карарлары һәм йөкләмәләре проектлары әзерләнергә мөмкин, алар билгеләнгән тәртиптә Идарә башлыгы каравына тапшырыла.

3.21. Комиссиянең әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карарлары утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышлары белән яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә (әгәр Комиссия бүтән карар кабул итмәсә).

3.22. Комиссия карарлары беркетмәләр рәвешендә рәсмиләштерелә, аларга Комиссия утырышында катнашкан Комиссия әгъзалары имза сала. Комиссия карарлары, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларыннан гайре, дәүләт органы җитәкчесе өчен тәкъдим итү характерында була. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карар үтәлеше буенча мәҗбүри характерда була.

3.23. Комиссия беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышының датасы, Комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) Комиссия утырышында каралучы һәр мәсьәләнең формулировкасы, үзенә карата хезмәттәге тәртипкә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга

салуга таләпләрне үтәү турында мәсьәлә каралучы дәүләт хезмәткәренең фамилиясен, исемен, атасының исемен, дәүләт хезмәте вазыйфасын күрсәтеп;

в) дәүләт хезмәткәренә белдерелүче дәгъвалар, аларны нигезләрлек материаллар;

г) дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның белдерелүче дәгъваларның асылы буенча аңлатып бтрүләре эчтәлеге;

д) утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм алар ясаган чыгышларның кыскача бәян ителеше;

е) Комиссия утырышын уздыру өчен нигез булган мәгълүматлы чыганак, мәгълүматның Идарәгә керү датасы;

ж) башка белешмәләр;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итү нигезе.

3.24. Комиссиянең карар белән килешмәгән әгъзасы үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, бу фикер Комиссия утырышы беркетмәсенә һичшиксез кушып куелырга тиеш һәм аның белән дәүләт хезмәткәрен таныштыру мәҗбүри.

3.25. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәләре утырыш көненнән соң 7 көнлек срокта – Идарә башлыгына, тулысынча яисә аңардан өземтәләр рәвешендә дәүләт хезмәткәренә җибәрелә, шулай ук Комиссия карары нигезендә кызыксынучы затларга җибәрелә.

3.26. Идарә башлыгы Комиссия беркетмәсен карарга тиеш һәм үз компетенциясе чикләрендә дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның бүтән мәсьәләләре буенча каралган җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул иткәндә андагы тәкъдимнәрне исәпкә алырга хокуклы. Комиссия тәкъдимнәрен карау һәм кабул ителгән карар турында Идарә башлыгы үзенә Комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән бер ай эчендә Комиссиягә язма рәвештә хәбәр итә. Идарә башлыгы карары Комиссиянең якындагы утырышында укып хәбәр ителә һәм фикер алышулардан башка гына искә алына.

3.27. Комиссия дәүләт хезмәткәре гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар гаепле хәл сыйфатларын ачыклаган очракта, бу хактагы мәгълүмат дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын күрү турында карар кабул итү өчен Идарә башлыгына тапшырыла.

3.28. Комиссия дәүләт хезмәткәре тарафыннан административ хокук бозу сыйфатлары яисә җинаять составы булган гамәлләр кылу фактын (гамәл кылмау фактын) ачыклаган очракта, Комиссия рәисе әлеге гамәл кылу (гамәл кылмау) турындагы мәгълүматны һәм мондый фактны раслаучы материалларны – 3 көнлек срок эчендә, ә кирәк булганда кичекмәстән хокук куллану органнарына тапшырырга тиеш.

3.29. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яисә аннан өземтә үзенә карата хезмәттәге тәртипкә таләпләрне үтәү һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга таләпләрне үтәү турында мәсьәлә каралучы дәүләт хезмәткәренең шәхси эше кәгазьләренә кушып куела.

3.30. Комиссия карарының Комиссия секретаре тарафыннан таныкланган һәм Идарә мөһере белән расланган өземтәсе Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын билүче, үзенә карата әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенча абзацында күрсәтелгән хезмәттәге тәртипкә таләпләрне үтәү һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга таләпләрне үтәү турында мәсьәлә каралучы дәүләт хезмәткәренә Комиссиянең тиешле утырышын уздырган көннән соң килүче беренче эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

3.31. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр турында, утырышны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат җибәрү, Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышында фикер алышуларга чыгарыла торган материаллар белән таныштыру Идарәнең кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.